ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

25 май 2026 ел

№ 4983

Башкарма комитетның «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4569 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Башкарма комитетның «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4569 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2021 елның 7 декабрендәге 7935 номерлы, 2022 елның 24 августындагы 4330 номерлы, 2023 елның 21 июнендәге 5412 номерлы, 2024 елның 23 гыйнварындагы 375 номерлы, 2024 елның 12 июлендәге 4581 номерлы, 2025 елның 13 гыйнварындагы 62 номерлы, 2025 елның 15 маендагы 3474 номерлы, 2025 елның 23 июнендәге 4512 номерлы, 2025 елның 22 августындагы 6170 номерлы, 2025 елның 21 октябрендәге 8540 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтада 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен тормышка ашыру буенча тәкъдимнәр эшләүдә катнашу;

2) җирле үзидарә органнары, шәһәр оешмалары һәм ГТХТС шәһәр звеносы көчләре эшчәнлеген координацияләү;

3) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын, гражданнар оборонасын тәэмин итү, шулай ук гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән һәм җимерелгән торак йортларны, торак-коммуналь хуҗалык объектларын, социаль өлкәне, җитештерү һәм инженерлык инфраструктурасын торгызу һәм төзү өлкәсендәге бурычларны хәл иткәндә, җирле үзидарә органнары һәм шәһәр оешмалары гамәлләренең килешенүен тәэмин итү;

4) федераль законда билгеләнгән тәртиптә, гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм бетерү чараларын оештыруга һәм үткәрүгә гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын җәлеп итү турындагы мәсьәләләрне карап тикшерү;

5) гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итүне һәм мәгълүмат бирүне оештыру турындагы мәсьәләләрне карап тикшерү.»;

2) 2 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 25 маендагы
4983 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2020 елның 14 сентябрендәге
4569 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү
һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе
составы

| № т/б | Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Салахов Фәрид Шавкат улы | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| 2. | Сәлимханов Илгизәр Әбүзәр улы | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 3. | Мифтахетдинов Алмаз Шәйхенур улы | комиссия рәисе урынбасары, ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Дәүләт янгынга каршы хезмәте федераль янгынга каршы хезмәтенең 15 нче янгын сүндерү-коткару отряды башлыгы (килешү буенча) |
| 4. | Шипеева Рамилә Климовна | комиссия секретаре, Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе мөдире |
| | | комиссия әгъзалары: |
| 5. | Әхмәтҗанов Ленар Илдар улы | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы |
| 6. | Әхмәтова Гөлнар Карл кызы | Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе |
| 7. | Әхмәтшин Ренат Рөстәм улы | Башкарма комитетының физик культура һәм спорт идарәсе башлыгы |
| 8. | Бәдртдинов Ренат Рәфкать улы | ТР буенча РФ ГТХМ Баш идарәсе Күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсенең «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| 9. | Видинеева Ләйсән Әлфит кызы | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| 10. | Вилданов Руслан Флер улы | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 11. | Кәрамиев Румил Рәүф улы | мәдәни кыйммәтләрне саклау хезмәте башлыгы, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы |
| 12. | Кашапов Нәркиз Венер улы | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе башлыгы |
| 13. | Кропотова Наталия Анатольевна | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 14. | Матросов Рәмзи Таһир улы | Башкарма комитетның мобилизация бүлеге башлыгы |
| 15. | Минегалиев Мөдәрис Харис улы | Башкарма комитет карамагындагы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 16. | Нәфигуллина Лемуза Рульевна | эпидемиягә каршы хезмәт башлыгы, Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше |

| | | |
|---|---|---|
| | | иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт идарәсенең Яр Чаллы шәһәрендәге, Актаныш, Тукай, Минзәлә районнарындагы территориаль бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 17. | Ногманов Рөстәм Марат улы | медицина хезмәте башлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| 18. | Ногуманов Әбүзәр Әгъзам улы | ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең кече суднолар буенча дәүләт инспекциясе үзегенең Яр Чаллы инспекторлык бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| 19. | Рогожникова Надежда Андреевна | ТР ГТХМ Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча идарәсе башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| 20. | Степанов Максим Александрович | «Таттелеком» ААҖ филиалы – Яр Чаллы зональ электр элемтәсе узелы директоры (килешү буенча) |
| 21. | Солтанова Рәисә Кәүсәр кызы | сәүдә һәм туклану хезмәте башлыгы, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенең кулланучылар базары бүлеге башлыгы |
| 22. | Фәттахов Мансур Әдип улы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 23. | Хәбибрахманов Рәшит Гыйлфан улы | ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү хезмәте башлыгы, «Татнефть-АЗС Центр» ҖЧҖнең Чаллы филиалы башлыгы (килешү буенча) |
| 24. | Хәбибуллин Фидәрис Фәндәвис улы | Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы |
| 25. | Хәмитов Фаил Фәнил улы | җәмәгать тәртибен саклау хезмәте башлыгы, Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы идарәсенең полиция (җәмәгать тәртибен саклау буенча) башлыгы урынбасары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| 26. | Харисов Винер Хәмит улы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 27. | Хаттапов Фәнис Сабир улы | ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең 6 нчы зональ эзләү-коткару отряды башлыгы (килешү буенча) |
| 28. | Хөснуллин Айрат Шәүкәт улы | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы |
| 29. | Черкашин Илья Игоревич | юл хезмәте башлыгы, «Автомобиль юллары предприятиесе» ҖЧҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| 30. | Шаронов Эдуард Павлович | энергетика хезмәте башлыгы, «Челтәрләр компаниясе» ААҖ филиалы - «Кама электр челтәрләре» директоры (килешү буенча) |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ • МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ